**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«31» октябрь 2025 ел № 7

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 29, 30, 31 октябрендә узган: «2026 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гэйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.
2) урамнарны яктырту җайланмасы.
3) су белән тәэмин итү һәм чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
4) торак пункт территориясен төзекләндерү.
5) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, тирәсен тоту, тәртипкә китерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 213 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 151 кеше катнашты.

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 134 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 17 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2026 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гэйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә

теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

урамнарны яктырту җайланмасы.

су белән тәэмин итү һәм чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

торак пункт территориясен төзекләндерү.

традицион җирләү урыннарын ремонтлау, тирәсен тоту, тәртипкә китерү мәсьәләләре буенча кабул ителгән карарны таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева